| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**2016 елның 12 мае** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1250** |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 01 октябрендәге 2220 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә өстәмәләр кертү турында

Мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 01 октябрендәге 2220 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенең текстына өстәмә абзац кертергә:

2 нче бүлектә "Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе" 2.7 нче пункт:

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге бүлекчәләренә Россия Федерациясе Пенсия фондыннан, шул исәптән ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасын һәм аңа тоташа торган ведомствоара мәгълүмати багланышлар региональ системаларын кулланып алырга мөмкинлек бирә торган мәгълүмати аралашу кертелгәннән соң, эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан физик зат файдасына исәпләнгән түләүләр һәм башка түләүләр суммасы турында белешмәләр, компенсация билгеләү

аның гаризасында күрсәтелгән ризалыгы белән, Россия Федерациясе Пенсия фондында булган белешмәләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең компенсация билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән аена кадәрге 12 айның соңгы 3 аенда башкарыла.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгы А.Н. Коршуновка әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүматат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интренет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин